ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.10.2019 г. Заинск № 569

**“Зәй муниципаль районы башкарма комитетының яңа редакциядә административ комиссиясе составын раслау турында” Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетының 1908нче (02.09.2014) карарына үзгәрешләр кертү турында”**

Кадрлар алышыну белән бәйле рәвештә, Зәй муниципаль районы Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты

## карар бирә:

1. “Зәй муниципаль районы башкарма комитетының яңа редакциядә административ комиссиясе составын раслау турында” (Зәй муниципаль районы башкарма комитетының 12нче(12.01.2015), 1365нче(30.06.2016), 152нче(09.02.2017), 1779нчы(04.12.2018), 06нчы(18.01.2019) карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетының 1908нче (02.09.2014) карары белән расланган административ комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) А.А. Хәмидуллинаны комиссия составыннан чыгарырга;

б) комиссия составына әгъза итеп, башкарма комитетның икътисад бүлеге баш белгече Алия Илсур кызы Фәйрушинаны кертергә;

в) комиссия әгъзасы Лоптова Татьяна Александровнаның вазифасы исемен түбәндәге редакциядә бирергә: «Зәй муниципаль районы башкарма комитетының эшләр идарәчесе”;

г) комиссия әгъзасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетының әйдәүче белгече Артамонова Кристина Игоревнаның фамилиясен, никахка керү сәбәпле, Шәйхетдинова дип үзгәртергә.

2. Яңа редакциядә расларга:

- административ комиссия составын (1нче кушымта);

- административ комиссиянең эш регламентын (2нче кушымта).

3. “Зәй муниципаль районы административ комиссиясе составы турында» башкарма комитет җитәкчесенең 57нче (07.03.2006ел) карарына өстәмәләр кертү турында” Зәй муниципаль районы башкарма комитетының 1782нче 25.07.2011ел) карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Юрист
Т.Р. Кашапов
3 12 14

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
башкарма комитетының
31.10.2019 ел _№569
карарына 1нче кушымта

**Административ комиссия составы**

Хафизов Илнар Фәнил улы - Зәй муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе

Нифатов Николай Александрович - Зәй муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары

Кашапов Тәлгать Рәфәгать улы - Зәй муниципаль районы башкарма комитетының административ комиссиясе баш белгече, комиссиянең җаваплы сәркатибе

**Комиссия әгъзалары:**

Гобәйдулина Ирина Владимировна - Зәй муниципаль районы башкарма комитетының ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге әйдәүче белгече

Кашафеева Лена Линир кызы - Зәй муниципаль районы башкарма комитетының әйдәүче белгече

Лоптова Татьяна Александровна - Зәй муниципаль районы башкарма комитетының эшләр идарәчесе

Рыбацкая Фәния Газизулла кызы - Зәй муниципаль районы башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге баш белгече

Фәйрушина Алия Илсур кызы - Зәй муниципаль районы башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгече

Шәйхетдинова Кристина Игоревна - Зәй муниципаль районы башкарма комитетының әйдәүче белгече

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
башкарма комитетыны
31.10.2019 ел №569
карарына 2нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы административ комиссиясе эше РЕГЛАМЕНТЫ**

Әлеге Регламент Зәй муниципаль районы административ комиссиясенең (алга таба – административ комиссия) эш тәртибен билгели.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Административ комиссия башкарма комитет җитәкчесенең 57нче(07.03.2006) карары белән «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 144нче (30.12.2005) Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) нигезендә төзелде.

1.2. Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.

1.3. Административ комиссия Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында каралган административ хокук бозулар турында эшләрне карау өчен төзелә торган даими нигездә эшләүче коллегиаль орган булып тора һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясе чикләрендә гамәлдә.

1.4. Административ комиссиянең бурычлары булып административ хокук бозу турындагы эшләрне һәрьяклап, тулы, объектив һәм үз вакытында карау, кабул ителгән карарның үтәлешен тәэмин итү, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү тора.

1.5. Административ комиссиянең вәкаләтләр срогы административ комиссиянең Зәй муниципаль районы башкарма комитеты вәкаләтләре срогына беренче утырышыннан башлана. Күрсәтелгән вакыт үткәннән соң

административ комиссия үз вәкаләтләрен яңа состав административ комиссиясенең беренче утырышы көненә кадәр гамәлгә ашыруны дәвам итә.

1.6. Административ комиссия әгъзасының вәкаләтләре Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда вакытыннан алда туктатыла.

1.7. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты административ комиссиянең яңа әгъзасын үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан административ комиссия әгъзасы урынына административ комиссия әгъзасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да соңга калмыйча билгеләргә тиеш.

1.8. Административ комиссиянең административ комиссиянең тулы исемен чагылдырган мөһере булырга мөмкин.

1.9. Административ комиссия төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп торуны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, Зәй муниципаль районы башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

## 2. Административ комиссия эшен оештыру

2.1. Административ комиссия Зәй муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнә торган административ комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, җаваплы сәркатибеннән һәм административ комиссия әгъзаларыннан (алга таба – административ комиссия әгъзалары) тора (килешү буенча).

2.2. Административ комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашыралар.

2.3. Административ комиссиянең шәхси һәм сан ягыннан составы 5 кешедән дә ким булмаган санда башкарма комитет җитәкчесе карары белән билгеләнә һәм так сан тәшкил итәргә тиеш.

2.4. Административ комиссия составына даими штат нигезендә административ комиссиянең җаваплы секретаре керә. Административ комиссиянең башка әгъзалары, әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган очраклардан тыш, административ комиссиядә җәмәгать башлангычларында эшлиләр.

2.5. Зәй муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе карары буенча административ комиссиянең башка әгъзалары үз вазыйфаларын даими түләнә торган нигездә җирле бюджет хисабына башкара алалар.

2.6. Административ комиссия рәисе рәис урынбасарлары һәм административ комиссиянең җаваплы секретаре арасында вазыйфаларны бүлә, Татарстан Республикасы Законы белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә аларның функцияләрен билгели.

2.7. Административ комиссия рәисе административ комиссия әгъзаларының, шулай ук административ комиссия рәисе урынбасары һәм җаваплы секретаренең квалификациясен күтәрү эшен оештыра.

2.8. Административ комиссия тарафыннан килүчеләрне кабул итү гамәлгә ашырыла. Килүчеләрне кабул итү тәртибе административ комиссия рәисе күрсәтмәсе белән билгеләнә.

2.9. Административ комиссия адресына кергән шикаятьләр һәм гражданнар, юридик затлар мөрәҗәгатьләре мөрәҗәгатьләрне һәм шикаятьләрне исәпкә алу журналында теркәлә, гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда карала һәм җаваплар җибәрелә

2.10. Административ комиссия төзекләндерү, чисталык һәм тәртипне тәэмин итү өлкәсендә контрольлек итә һәм Зәй муниципаль районы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау эшен алып бара. Контроль үткәрү тәртибе һәм контроль үткәрү планы административ комиссия рәисе тарафыннан раслана.

2.11. Административ хокук бозулар буенча эшләр административ комиссиядә саклана, һәм 3 ел үткәннән соң исәптән төшерү турындагы акт нигезендә юкка чыгарылырга тиеш.

2.12. Административ комиссия эшчәнлеген яхшырту максатларында суд-арбитраж практикасын даими гомумиләштерү үткәрелә.

Суд-арбитраж практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен исәпкә алып, законнарны өйрәнү һәм хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү буенча эш оештырыла.

2.13. Административ комиссия тарафыннан билгеләнгән форма буенча хисап эше алып барыла.

Әлеге белешмәләр Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча квартал саен тапшырыла.

2.14. Законда каралган очраклардан тыш, мөрәҗәгать итүчеләргә административ хокук бозулар турында эшләрне бирү тыела.

2.15. Административ комиссиядә мәгълүмати-белешмә эше алып барыла.

## 3. Административ комиссия утырышын чакыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә административ комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.2. Административ хокук бозулар турындагы эшләр утырышларда административ комиссия тарафыннан карала. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр һәм башка материаллар кергән очракта, административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карар аның рәисе тарафыннан кабул ителә, ә ул булмаганда – рәис тарафыннан билгеләнә торган рәис урынбасарларының берсе, ләкин айга 2 тапкырдан да ким түгел.

3.3. Административ комиссия утырышлары административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау срокларын үтәүне тәэмин итә торган ешлык белән үткәрелә.

3.4. Административ комиссиянең җаваплы секретаре административ комиссия утырышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында административ комиссия утырышына кадәр 3 көн алдан хәбәр итә.

3.5. Административ комиссия утырышында катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм әгъзалары бу хакта административ комиссия утырышына кадәр, кагыйдә буларак, бер көн алдан җаваплы секретарена хәбәр итәргә тиешләр.

3.6. Административ комиссия утырышы, административ комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы була.

3.7. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карар, билгеләмә утырышта катнашучы административ комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.8. Административ комиссия утырышлары ачык булып тора. Аларда массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә катнаша ала.

3.9. Утырышның коллегиаль органы карары буенча алар ябык булырга мөмкин. Аларда бары тик комиссия әгъзалары, хокук саклау органнарының вазыйфаи затлары һәм махсус чакырылган затлар гына катнашырга хокуклы.

3.10. Административ комиссия утырышы вакытында кино-, видео - һәм фотога төшерү рәис рөхсәте белән башкарыла.

3.11. Рәислек итүче административ хокук бозу турындагы эшне карау өчен билгеләнгән вакытта утырышны ача, комиссия составын игълан итә, хокук һәм бурычларны аңлата, утырышны алып бару тәртибен билгели, административ процесста катнашучыларның гариза, үтенечнамәләре бармы икәнне белешә, утырыш белән җитәкчелек итә, утырыш барышында тиешле тәртип саклауны тәэмин итә.

3.12. Административ комиссия каравына кертелгән мәсьәләләр буенча суд практикасын күзәтү (гомумиләштерү) рәвешендә материаллар тапшырыла.

3.13. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау чиратлылыгы хәбәрнамәләр белән билгеләнә. Кирәк булганда, административ комиссия әлеге чиратны үзгәртергә хокуклы.

3.14. Административ хокук бозу турындагы эшне карау рәислек итүченең административ материалда бәян ителгән хәл турындагы докладыннан башлана. Доклад ахырында административ комиссия әгъзалары карала торган эшнең асылы буенча сораулар бирергә хокуклы.

3.15. Административ комиссиянең һәр утырышында административ хокук бозу турындагы эшне карау турында беркетмә алып бару мәҗбүри.

## 4. Административ комиссия карары

4.1 Административ комиссия карарына рәислек итүче имза сала.

4.2.Бер үк вакытта утырышта катнашучы затларга һәм аларның вәкилләренә административ комиссия карарына шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

4.3. Карарның күчермәсе физик затка яисә физик затның законлы вәкиленә, яисә юридик затның законлы вәкиленә расписка белән тапшырыла яисә күрсәтелгән затларга әлеге карар чыгарылган көннән соң өч көн эчендә җибәрелә.

4.4. Административ комиссия карарларының вакытында тапшырылуын һәм күчермәләрен җибәрүне контрольдә тоту җаваплы сәркатипкә йөкләнә.

4.5. Административ комиссиянең законлы көченә кергән карарын үтәү Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.

4.6. Административ комиссия карарларына карата шикаятьләр яисә протестлар административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә карала.

## 5. Административ хокук бозуларны профилактикалау

5.1. Административ хокук бозуларны кисәтү максатларында административ комиссия үз эшчәнлеген эчке эшләр органнары, суд приставлары федераль хезмәте идарәсенең территориаль бүлекләре, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, башка органнар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән координацияли.

5.2. Административ комиссия рәис раслаган график нигезендә күчмә утырышлар үткәрә, шул исәптән муниципаль район җирлекләренә.

5.3. Административ комиссия профилактика эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту һәм халык арасында аңлату эшләре алып бару юлы белән оештыра.